РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12,
г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 3 феврале № 4

Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 38 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы нигездә ия булуга һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек Исемлеген раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлеше, 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалаган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон ( үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 38 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы нигездә ия булуга һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек Исемлеген раслау турында» карары кушымтасына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә аны мөлкәт белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазифаларын башкаручы,
Мэры урынбасары

Э.Р. Долотказина

Түбән Кама шәһәр Советының
2020 елның 3 февралендәге
4 номерлы карарына кушымта

| т/с | Адрес | Исәпкә алу объектының исеме | Объектның характеристикасы, мәйданы, кв. м. |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Студентлар урамы, 13 нче йорт, 1006 нчы урын | 16:53:040205:2309 кадастр номерлы, 1006 нчы номерлы торак булмаган урын | 456,7 кв. м мәйданлы административ бинаның 3 нче катында торак булмаган урын |

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

Э.Р. Долотказина